| | | |
|---|---|---|
| **МИНИСТЕРСТВО ЗДРАВООХРАНЕНИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ СӘЛАМӘТЛЕК САКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ** |
| **ПРИКАЗ** | | **БОЕРЫК** |
| **12.12.2019** | г. Казань | № **2464** |

Татарстан Республикасында
мәҗбүри медицина иминияте
акчалары хисабына экстракорпораль
аталандыру процедурасын уздыруны
оештыру турында

Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтүнең Дәүләт гарантияләре программасы акчалары хисабына экстракорпораль аталандыру процедурасын уздыруны оештыру максаты белән, 2012 елның 30 августыннан №107н «Ярдәмче репродуктив технологияләрне куллану тәртибе, аларны куллануга каршы күрсәтмәләр һәм чикләүләр турында», 2012 елның 30 октябреннән № 556н «Балага уза алмаганда ярдәмче репродуктив технологияләрне куллану белән медицина ярдәме стандартын раслау турында» Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының боерыкларын үтәү йөзеннән б о е р а м:

1. Кушымта итеп бирелгәннәрне расларга:

Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтүнең Дәүләт гарантияләре программасы (алга таба – ММИ программасы) акчалары хисабына экстракорпораль аталандыру (алга таба – ЭКО) процедурасын уздыру өчен пациентларны сайлап алу һәм «Көтү битенә» кую алгоритмы (Кушымта № 1);

ЭКО процедурасын уздыру өчен ММИ программасында катнашучы медицина оешмалары исемлеге (Кушымта № 2);

ММИ программасын тормышка ашыруда катнашучы медицина оешмаларында мәҗбүри медицина иминияте акчалары хисабына ЭКО процедурасын уздыру алгоритмы (Кушымта № 3);

Балага уза алмауны дәвалаганда ярдәмче репродуктив технологияләр куллану белән медицина ярдәмен күрсәтү буенча Республика Комиссиясе (алга таба – Республика комиссиясе) турында нигезләмә (Кушымта № 4);

Якынча формалар:

Пациентның амбулатор картасыннан өземтә (Кушымта № 5);

Балага уза алмауны дәвалаганда ярдәмче репродуктив технологияләр куллану белән медицина ярдәмен күрсәтү буенча Республика Комиссиясенә пациентның медицина документларын җибәрү (җибәрүдән баш тарту) турында медицина оешмасының табиблар комиссиясе карарының беркетмәсе (Кушымта № 6);

Балага уза алмауны дәвалаганда ярдәмче репродуктив технологияләр куллану белән медицина ярдәмен күрсәтү буенча Республика Комиссиясе карарының беркетмәсе (Кушымта № 7);

ММИ программасы акчалары хисабына ЭКО процедурасын уздыру өчен юллама (Кушымта № 8);

ММИ программасы акчалары хисабына ЭКО процедурасын уздыру өчен пациент гаризасы (Кушымта № 9);

Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык (Кушымта № 10);

ММИ программасы акчалары хисабына ЭКО процедурасын уздыру өчен медицина оешмасына җибәрелгән пациентның килүе/килмәве турында белдермә (Кушымта № 11);

ММИ программасы акчалары хисабына ЭКО процедурасын уздыру өчен юллама буенча ЭКО процедурасын үткәрүче медицина оешмасы турында белешмәләр (Кушымта № 12);

«Көтү кәгазе» (Кушымта № 13);

ММИ программасы акчалары хисабына ЭКО яки криокүчерүдән соң диагностикаланган йөклелеге булган пациенткаларның отчет-реестры (Кушымта № 14);

ММИ программасы акчалары хисабына ЭКО процедураларын уздыруның нәтиҗәлелеге турында белешмәләр (Кушымта № 15);

ММИ программасы акчалары хисабына «Криокүчерү» процедураларын үткәрүнең нәтиҗәлелеге турында белешмәләр (Кушымта № 16);

ММИ программасы акчалары хисабына ЭКО, шул исәптән «Криокүчерү» процедурасын үткәрү нәтиҗәсендә барлыкка килгән йөклелек һәм бала табу нәтиҗәләре турында мәгълүмат (Кушымта № 17);

Отчет периодында стационар дәвалауны алган һәм ЭКО, шул исәптән «Криокүчерү» процедурасыннан өзлегүләре булган пациентлар турында мәгълүмат (Кушымта № 18);

Эмбрионнарны стимуляцияләү картасын һәм культивацияләү картасын кушымта итеп бирү белән пациентның шәхси картасыннан өземтә (ЭКО процедурасыннан соң) (Кушымта № 19);

«Көтү битеннән» төшерелгән ММИ программасы акчалары хисабына ЭКО процедурасын үткәрүгә мохтаҗ булмаган пациентлар реестры (Кушымта № 20);

ММИ программасы акчалары хисабына үткәрелгән ЭКО һәм «Криокүчерү» процедуралары турында белешмәләр (Кушымта № 21);

ММИ программасы акчалары хисабына ЭКО процедурасын узган пациентлар турында белешмәләр (Кушымта № 22).

2. Мәҗбүри медицина иминияте өлкәсендә эшчәнлек башкаручы медицина оешмалары Реестрына кертелгәннәр арасыннан акушерлык һәм гинекология буенча беренчел махсуслаштырылган медик-санитар ярдәм (ярдәмче репродуктив технологияләрне (алга таба – ЯРТ) кертмичә) күрсәткәндә эшләр башкаруны (хезмәтләр күрсәтүне) күздә тоткан медицина эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензиясе булган сәламәтлек саклау учреждениеләре җитәкчеләренә:

2.1. 2012 елның 30 августыннан №107н «Ярдәмче репродуктив технологияләрне куллану тәртибе, аларны куллануга каршы күрсәтмәләр һәм

чикләүләр турында» Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының боерыгына (алга таба – 2012 елның 30 августыннан №107н РФ ССМ боерыгы), шулай ук әлеге Боерыкка туры китереп, пациентларның балага уза алмавын ачыклау өчен аларны карап тикшерүне һәм ММИ программасы акчалары хисабына ЭКО процедурасын уздыруга мохтаҗ булган, Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән Россия Федерациясе гражданнарына ЯРТ куллану белән медицина ярдәме күрсәтү өчен акушерлык һәм гинекология буенча беренчел махсуслаштырылган медик-санитар ярдәм күрсәткәндә (шул исәптән ЯРТ куллану белән) эшләр башкаруны (хезмәтләр күрсәтүне) күздә тоткан медицина эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензиясе булган медицина оешмаларына пациентларны җибәрүне тәэмин итәргә;

2.2. ЭКО процедурасы нәтиҗәсендә йөклелек барлыкка килгәч, медицина хезмәте күрсәтү урыны буенча хатын-кызны күзәтүне оештырырга (кирәк булган очракта – ЭКО процедурасы уздырылган медицина оешмасы белгечләренең консультациясе).

2.3. Ай саен отчет бирү аеннан соң килгән айның 2 нче числосына кадәр булган срокта, әлеге Боерыкка кушымта № 23 туры китереп, Республика Комиссиясенә ММИ программасы акчалары хисабына үткәрелгән ЭКО процедурасы нәтиҗәсендә барлыкка килгән йөклелек һәм бала табу буенча учетка баскан хатын-кызлар саны турында мәгълүматны җиткерүне тәэмин итәргә. Отчетларны Республика Комиссиясенә электрон почта аша түбәндәге адрес буенча җибәрергә: Comvrt.Rt@tatar.ru.

3. Мәҗбүри медицина иминияте өлкәсендә эшчәнлек башкаручы медицина оешмалары Реестрына кертелгәннәр арасыннан акушерлык һәм гинекология буенча беренчел махсуслаштырылган медик-санитар ярдәм (шул санда ЯРТ куллану белән) күрсәткәндә эшләр башкаруны (хезмәтләр күрсәтүне) күздә тоткан медицина эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензиясе булган сәламәтлек саклау учреждениеләре җитәкчеләренә:

3.1. 2012 елның 30 августыннан №107н РФ ССМ боерыгына, шулай ук әлеге Боерыкка туры китереп, ММИ программасы акчалары хисабына ЭКО процедурасын уздыруга мохтаҗ булган, Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән Россия Федерациясе гражданнарына ярдәмче репродуктив технологияләрне куллану белән медицина ярдәме күрсәтү өчен пациентларны карап тикшерүне тәэмин итәргә;

3.2. ЭКО алымы белән дәвалау күрсәтелгән балага уза алмый торган пациенткалар ачыкланганда, әлеге Боерыкка кушымталар № 5, 6, 9, 10 туры китереп, документларны рәсмиләштерүне һәм Республика Комиссиясенә тапшыруны тәэмин итәргә;

3.3. Пациентларны ММИ программасы акчалары хисабына ЭКО процедурасына сайлап алу, юнәлтү һәм балага уза алмауны дәвалаганда ярдәмче репродуктив технологияләр куллану белән медицина ярдәмен күрсәтү буенча Республика Комиссиясенә пациент документларын җибәрү өчен җаваплы затларны билгеләргә (алга таба – Җаваплы зат);

3.4. ММИ программасы акчалары хисабына ЭКО процедурасын уздыру өчен оешманы сайлаган пациенткалар реестрын «Көтү кәгазенә» туры китереп алып барырга;

3.5. ММИ программасы акчалары хисабына ЭКО процедурасын куллану белән пациентларга медицина ярдәмен күрсәтүне 2012 елның 30 августыннан №107н РФ ССМ боерыгына, 2012 елның 30 октябреннән № 556н «Балага уза алмаганда ярдәмче репродуктив технологияләрне куллану белән медицина ярдәме стандартын раслау турында» Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының боерыгына (алга таба – 2012 елның 30 октябреннән № 556н РФ ССМ боерыгы) туры китереп тәэмин итәргә;

3.6. ЭКО процедурасын уздырганнан соң өзлегүләре булган пациенткаларны госпитализацияләүне оештырырга;

3.7. Квартал саен отчет бирү периодыннан соң килгән айның 2 нче числосына кадәр булган срокта Республика комиссиясенә ЭКО өзлегүләре турында хисап тапшыруны тәэмин итәргә (Кушымта № 18);

3.8. Ай саен отчет бирү аеннан соң килгән айның 2 нче числосына кадәр булган срокта, әлеге Боерыкка кушымта № 14 туры китереп, Республика Комиссиясенә ММИ программасы акчалары хисабына ЭКО процедурасы үткәрелгән пациентларның отчет-реестрын тапшыруны тәэмин итәргә;

3.9. Ай саен отчет бирү периодыннан соң килгән айның 15 нче числосына кадәр булган срокта, әлеге Боерыкка кушымталар № 12, 15, 16, 20 туры китереп, Республика Комиссиясенә отчетларны тапшыруны тәэмин итәргә.

3.10. Ай саен отчет бирү аеның соңгы көненең 17.00 сәгатенә кадәр булган срокта, әлеге Боерыкка кушымта № 21 туры китереп, Республика Комиссиясенә үткәрелгән ЭКО процедуралары, шул исәптән «Криокүчерүләр» турында мәгълүматларны тапшыруны тәэмин итәргә.

3.11. Отчетларны Республика Комиссиясенә электрон почта аша түбәндәге адрес буенча җибәрергә: Comvrt.Rt@tatar.ru.

4. Бала тудыру йортларының һәм перинаталь үзәкләрнең баш табиблары ай саен отчет бирү аеннан соң килгән айның 2 нче числосына кадәр булган срокта, әлеге Боерыкка кушымта № 17 туры китереп, Республика Комиссиясенә ММИ программасы акчалары хисабына ЭКО процедурасы үткәрү нәтиҗәсендә барлыкка килгән йөклелекнең һәм бала табуның нәтиҗәсе турында мәгълүматны түбәндәге адрес буенча җибәрергә тиеш: Comvrt.Rt@tatar.ru.

5. Республика Комиссиясенә тәэмин итәргә:

5.1. ММИ программасы акчалары хисабына ЭКО процедурасын үткәрүгә мохтаҗ пациентларның документларын кабул итү.

5.2. Әлеге Боерыкка кушымталар № 14, 15, 16, 17, 18, 20, 21, 22 туры китереп, ММИ программасы акчалары хисабына ЭКО процедурасын уздыруга мохтаҗ пациентларга медицина ярдәме күрсәтү мониторингын алып бару.

5.3. Ай саен отчет бирү аеннан соң килгән айның 5 нче числосына кадәр булган срокта, әлеге Боерыкка кушымталар № 14, 15, 16, 17, 18, 20, 21, 22 туры китереп, Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгының Дәвалау һәм профилактик ярдәм күрсәтү идарәсенең балаларга медицина ярдәмен һәм бала табуга ярдәм итә торган хезмәтне оештыру бүлегенә һәм Татарстан Сәламәтлек

саклау министрлыгының югары технологияле медицина ярдәмен оештыру бүлегенә ММИ программасы акчалары хисабына ЭКО процедурасы уздырылган пациентларның отчет-реестрын, ММИ программасы акчалары хисабына уздырылган ЭКО процедурасы нәтиҗәсендә барлыкка килгән йөклелекнең һәм бала табуның нәтиҗәләре турында мәгълүматны тапшыруны тәэмин итәргә.

5.4. ММИ программасы акчалары хисабына ЭКО процедурасы күрсәтелгән Татарстан Республикасы халкының шәхси исәбен, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының «Диспетчерлык үзәге. Югары технологияле медицина ярдәме» Мәгълүмат-аналитика системасында (алга таба – «ДҮ. ЮТМЯ» МАС) «Көтү кәгазе» регистрын алып баруны тәэмин итү.

6. «Татарстан Республикасы Территориаль Мәҗбүри медицина иминияте фонды» Дәүләт учреждениесе директоры А.М. Мифтаховага ай саен отчет аеннан соң килүче айның 15 нче числосына кадәр срокта билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Икътисадый анализ һәм фаразлау идарәсенә ММИ программасы акчалары хисабына ЭКО процедурасын үткәрүдә катнашучы медицина оешмалары киселешендә ЭКО очракларының түләнгән счет-реестрлары турында мәгълүматны тапшырырга тәкъдим итәргә.

7. Әлеге Боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министрының беренче урынбасары А.Р. Абашевка йөкләргә.

Министр М.Н. Садыйков

2019 елның 12 декабреннән
№ 2464 ТР Сәламәтлек саклау
министрлыгы боерыгына
Кушымта № 1

Татарстан Республикасы территориясендә
Гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасы акчалары хисабына экстракорпораль аталандыру процедурасын уздыру өчен пациентларны сайлап алу һәм «Көтү битенә» кую алгоритмы

1. Әлеге Алгоритм ММИ программасы акчалары хисабына пациентларны ЭКО процедурасына сайлап алуны һәм «Көтү битенә» куюны оештыру мәсьәләләрен регламентлый.

2. ММИ программасы акчалары хисабына ЭКО алымы белән дәвалану узарга Татарстан Республикасы территориясендә ММИ буенча иминиятләштерелгән, ММИ программасы кысаларында түләүсез медицина ярдәме күрсәтү хокукына ия булган пациентлар мөмкиннәр.

3. Күрсәтмәләр, ярамаган күрсәтмәләр исемлеге, пациентларны тикшерү күләме һәм ЭКО процедурасын үткәрүгә хәзерләү 2012 елның 30 августыннан № 107 РФ ССМ боерыгы белән билгеләнгән.

4. 2012 елның 30 августыннан № 107 РФ ССМ боерыгы белән, 2018 елның 28 декабреннән «Хатын-кыз балага уза алмаулыгы (диагностикага һәм дәвалауга хәзерге заман алымнары)» Россия ССМ Клиник рекомендацияләре (дәвалау беркетмәсе) белән билгеләнгән овуляцияне стимуллаштыруга түбән җавап булуга югары ихтимал белән, эмбрионнарның түбән сыйфаты һәм ярдәмче репродуктив технологияләр программаларында йөклелек җитүнең түбән мөмкинлекләре белән ассоциацияләнгән билгеләр ЭКО алымы белән дәвалауның база программасын үткәрү өчен чикләүләр булып торалар, ә атап әйткәндә:

- антимюллерлы гормонның дәрәҗәсе 0,5 нг/мл кимрәк булуы;
- фолликулостимуллаштыручы гормон дәрәҗәсе (ФСГ) 12 МЕ/л һәм аннан да күбрәк булуы;
- ике күкәйлектә дә антраль фолликуллар саны (АФС) 3тән кимрәк булуы (менструаль циклның 3-5 көнендә үткәрелгән ультратавыш тикшеренүләре мәгълүматлары буенча).

5. 4 пунктта күрсәтелгән билгеләр булу ММИ программасы акчалары хисабына ЭКО процедурасын үткәрүдән баш тарту өчен нигез булып тора.

6. Балага уза алмауны ачыклау максатында (1 этап) гаилә парларын алдан тикшерү акушерлык һәм гинекология буенча беренчел махсуслаштырылган медик-санитар ярдәм (ЯРТ куллануны кертмичә) күрсәткәндә эшләр башкаруны (хезмәтләр күрсәтүне) күздә тоткан медицина эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензиясе булган медицина оешмаларында гамәлгә ашырыла.

7. 1 этапта «Балага уза алмый торган» диагнозы ачыкланганда диагнозны аныклау һәм дәвалау тактикасын сайлау (2 этап) максаты белән пациентлар мәҗбүри медицина иминияте өлкәсендә эшчәнлек башкаручы медицина оешмалары Реестрына кертелгәннәр арасыннан акушерлык һәм

гинекология буенча беренчел махсуслаштырылган медик-санитар ярдәм күрсәткәндә (шул исәптән ЯРТ куллану белән) эшләр башкаруны (хезмәтләр күрсәтүне) күздә тоткан медицина эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензиясе булган медицина оешмаларына 2012 елның 30 августыннан № 107н РФ ССМ боерыгы таләпләренә туры китереп җибәреләләр.

8. ММИ программасы акчалары хисабына ЭКО процедурасын уздыру өчен медицина күрсәтмәләре булган һәм каршы күрсәтмәләре булмаган очракта, мәҗбүри медицина иминияте өлкәсендә эшчәнлек башкаручы медицина оешмалары Реестрына кертелгәннәр арасыннан акушерлык һәм гинекология буенча беренчел махсуслаштырылган медик-санитар ярдәм күрсәткәндә (шул исәптән ЯРТ куллану белән) эшләр башкаруны (хезмәтләр күрсәтүне) күздә тоткан медицина эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензиясе булган медицина оешмасының табиблар комиссиясе 2012 елның 30 августыннан № 107н РФ ССМ боерыгы таләпләренә туры китереп пациентның документларын Республика Комиссиясе тарафыннан карап тикшерүгә җибәрү турында карар чыгара һәм пациенткага сайлау ясау өчен ЭКО процедурасын үткәрү өчен ММИ программасында катнашучы медицина оешмаларының исемлеген (Кушымта №2) бирә.

9. Медицина оешмасының табиблар комиссиясе Республика Комиссиясенә җибәрү өчен 2 нөсхәдә документлар исемлеген төзи.

10. Республика Комиссиясенә җибәрү өчен документлар исемлеге үз эченә ала:

әлеге боерыкка кушымта № 6 туры китереп, балага уза алмауны дәвалаганда ярдәмче репродуктив технологияләр куллану белән медицина ярдәмен күрсәтү буенча Республика Комиссиясенә пациентның медицина документларын җибәрү (җибәрүдән баш тарту) турында медицина оешмасының табиблар комиссиясе карарының беркетмәсе;

әлеге боерыкка кушымта № 5 туры китереп, учреждениенең мөһере белән расланган, медицина оешмасының җитәкчесе имзасы куелган диагнозны раслаучы лаборатор, инструменталь һәм башка тикшеренүләр нәтиҗәләре белән пациентның амбулатор картасыннан өземтә;

әлеге боерыкка кушымта № 9 туры китереп, ЭКО процедурасын алырга тели торган медицина оешмасы исемен күрсәтеп, ММИ программасы акчалары хисабына ЭКО процедурасын уздыру өчен пациентның гаризасы;

пациент документларының күчермәләре: паспорт, мәҗбүри медицина иминияте полисы; гражданинның мәҗбүри пенсия иминияте системасында шәхси счетының иминият номеры (СНИЛС);

әлеге боерыкка кушымта № 10 туры китереп, шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык.

11. Әлеге кушымтаның 10 пунктында күрсәтелгән документларның гамәлдә булу срогы табиблар комиссиясе тарафыннан пациент документларын Республика Комиссиясенә карап ткшерүгә җибәрү турында карар кабул ителгәннән соң 30 эш көненнән дә артмый.

12. Документлар исемлеге Республика Комиссиясенә бер нөсхәдә җибәрелә (документлар почта аша, хәбәрнамә белән яисә курьер тарафыннан җибәрелә).

13. Республика Комиссиясе секретаре документларны терки, номер бирә һәм пациентларның документлар пакетын Республика Комиссиясе утырышына тапшыра.

14. Республика Комиссиясе Республика Комиссиясе турындагы нигезләмәгә (әлеге боерыкка Кушымта № 4) туры китереп ММИ программасы акчалары хисабына ЭКО процедурасын үткәрүгә мохтаҗ пациентларны сайлап алуны гамәлгә ашыра, пациентны ММИ программасы акчалары хисабына ЭКО процедурасын уздыру өчен «Көтү битенә» кую яки баш тарту турында карар кабул итә. Утырыш нәтиҗәләре буенча әлеге боерыкка кушымта № 7 туры китереп Республика Комиссиясе карары беркетмәсе төзелә.

15. Республика комиссиясе утырышыннан соң секретарь 10 эш көне эчендә пациент документларын җибәргән медицина оешмасының җаваплы затына «Көтү битенә» кую турында Республика Комиссиясе карары беркетмәсе» (әлеге боерыкка Кушымта № 7) һәм «Көтү бите» (әлеге боерыкка Кушымта № 13) җибәрә.

16. Медицина оешмасының җаваплы заты 10 эш көне эчендә пациентка «Көтү кәгазен» (әлеге боерыкка Кушымта № 13) шәхсән тапшыра һәм үзе сайлаган оешмага ЭКО процедурасын уздыру өчен «Көтү кәгазендә» «Киләсе бару датасы» пунктында күрсәтелгән срокта мөрәҗәгать итәргә кирәклеген аңлата.

17. «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Диспетчерлык үзәге» ТР ДАУ «ДҮ. ЮТМЯ» мәгълүмат-аналитик системасында Республика Комиссиясе карары Беркетмәсен беркетү белән пациент талонын рәсмиләштерә.

18. ЭКО процедурасын уздыру өчен оешмалар исемлегенә кертелгән медицина оешмасы Республика Комиссиясе Беркетмәләре нигезендә әлеге оешманы сайлаган пациентлар реестрын төзи.

19. Пациентканың элек сайлаган клиниканы алыштырырга теләве очрагында, ул Республика комиссиясе секретаренә шәхсән мөрәҗәгать итә, кабат гариза яза (әлеге боерыкка Кушымта № 10). Яңа «Көтү бите» алганнан соң 30 көн эчендә пациент үзе сайлаган клиникага мөрәҗәгать итә.

20. Республика Комиссиясе тарафыннан пациентканы өстәмә тикшерүнең кирәклеге турында карар кабул ителгән очракта, әлеге кушымтаның 10 пунктында күрсәтелгән документлар исемлеген 1 нөсхәдә Республика Комиссиясе секретаре, эшләп бетерү һәм Республика Комиссиясе карап тикшерүенә кабат җибәрү өчен, Республика Комиссиясенә җибәргән җаваплы медицина оешмасының җаваплы затына кире кайтара.

2019 елның 12 декабреннән
№ 2464 ТР Сәламәтлек саклау
министрлыгы боерыгына
Кушымта № 2

ЭКО процедурасын үткәрү өчен ММИ программасында катнашучы медицина оешмалары исемлеге*

1. «АВА-ПЕТЕР» ҖЧҖнең Казан филиалы, Казан шәһ., Гвардия ур., 52/2 йорт;
2. «АВА-Казан» АҖ, Казан шәһ., Астрономия/Профсоюз ур., 19/15 йорт;
3. «ВРТ» ҖЧҖ, Казан шәһ., Бертуган Касыймовлар ур., 40а йорт;
4. «Нуриевлар Клиникасы Яр Чаллы» ҖЧҖ, Яр Чаллы шәһ., Г. Тукай Яр буе ур., 1/4А йорт;
5. «Гаилә медицинасы клиникасы» ҖЧҖ, Казан шәһ., Ямашев пр., 48Б йорт;
6. «КОРЛ» ҖЧҖ, Казан шәһ., Даурия ур., 12 йорт;
7. «Ана һәм бала Казан» ҖЧҖ, Казан шәһ., Даурия ур., 34а йорт.

* ЭКО процедурасын үткәрү өчен ММИ программасында катнашучы медицина оешмалары исемлеге ел саен раслана

2019 елның 12 декабреннән
№ 2464 ТР Сәламәтлек саклау
министрлыгы боерыгына
Кушымта № 3

**ММИ программасын тормышка ашыруда катнашучы медицина оешмаларында мәҗбүри медицина иминияте акчалары хисабына ЭКО процедурасын уздыру алгоритмы**

1. Агымдагы елның 8 гыйнварыннан башлап 31 мартына кадәр медицина оешмасын сайлаган пациентлар реестры нигезендә әлеге оешманың җаваплы заты пациентларга «Көтү кәгазенә» туры китереп ММИ программасы хисабына ЭКО алымы белән балага уза алмауны дәвалауны уздыру мөмкинлеге турында телефон аша хәбәр итә.
2. Пациент аңа хәбәр ителгәннән соң 30 көн эчендә үзе сайлаган клиникага мөрәҗәгать итә. Пациентның күрсәтелгән срок (30 көн) эчендә җитди сәбәпсез килмәве аны «Көтү битеннән» төшереп калдыру өчен нигез булып тора.
3. Медицина оешмасының җаваплы заты һәр айның 14 һәм 28 числосында Республика комиссиясе секретаренә «Көтү битләре» нигезендә һәм агымдагы елга финанслауның бүлеп бирелгән күләме кысаларында формалаштырылган ЭКО алымы белән балага уза алмауны дәвалауга мохтаҗ пациентларның актуаль исемлекләрен җибәрә.
4. Хәбәрнамәдән соң пациентка клиникага билгеләнгән срокларда килмәгән очракта, шулай ук пациентка дәвалануга мохтаҗ булмаган очракта, медицина оешмасының җаваплы заты әлеге пациентларның исемлеген әлеге боерыкка Кушымта № 11 туры китереп Республика комиссиясенә тапшыра.
5. «Көтү битеннән» төшерү турындагы карар Республика комиссиясе Беркетмәсе (әлеге боерыкка Кушымта № 7) белән рәсмиләштерелә, ул медицина оешмасына тапшырыла.
6. Медицина оешмасы тарафыннан пациентның килүе расланганда, Республика комиссиясе пациентларның документларын карап тикшерә һәм ЭКО алымы белән балага уза алмауны дәвалауга җибәрү турында карар кабул итә. Республика комиссиясенең юлламасы беркетмә белән рәсмиләштерелә (әлеге боерыкка Кушымта № 8).
7. Республика комиссиясе секретаре айга 2 тапкыр (14 һәм 28 числода) медицина оешмасының җаваплы затына түбәндәге документларны тапшыра:

Пациентны ЭКО процедурасын уздыру өчен пациент үзе сайлаган медицина оешмасына җибәрү турында Республика комиссиясе карары беркетмәсе (әлеге боерыкка Кушымта № 7);

Дәвалауга юллама (әлеге боерыкка Кушымта № 8).

8. Пациентка үзе сайлаган медицина оешмасына мөрәҗәгать иткәндә дәвалаучы табиб дәвалау планы төзи.
9. План төзелгәннән соң 2 ай дәвамында дәвалануга пациентка килмәгән очракта, медицина оешмасының җаваплы заты ай саен 5 числога кадәр Республика комиссиясе секретаренә «ММИ программасы акчалары хисабына

ЭКО процедурасын уздыру өчен медицина оешмасына җибәрелгән пациентның килүе/килмәве турында хәбәрнамәне» әлеге боерыкка Кушымта № 11 туры китереп җибәрә.

10. Дәвалау тәмамланганнан соң, дәвалаучы табиб пациенткага әлеге боерыкка Кушымта № 19 туры китереп шәхси картадан өземтә бирә.

11. ЭКО процедурасына әзерлек этабында каршы күрсәтмәләр ачыклаганда ЭКО процедурасын уздыру планлаштырыла торган медицина оешмасы 10 эш көне эчендә Республика комиссиясенә пациентканың медицина документларын ЭКО процедурасын үткәрүнең максатчанлыгын билгеләү максаты белән кабат карап тикшерүгә җибәрә.

12. Балага уза алмаган пациентларга Эко алымы белән медицина ярдәме күрсәтү 2012 елның 30 октябреннән № 556н һәм 2012 елның 30 октябреннән № 107н РФ ССМ боерыкларына, «Хатын-кызлар балага уза алмавы (диагностикалауга һәм дәвалауга хәзерге заман алымнары)» һәм «Ярдәмче репродуктив технологияләр һәм ясалма инсеминация» 2018 елның 28 декабреннән Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының клиник рекомендацияләренә (дәвалау беркетмәләре) туры китереп гамәлгә ашырыла.

13. ЭКО процедурасын үткәргәннән соң йөклелек барлыкка килмәгәндә пациентлар «Көтү битенә» кабат керә алалар.

14. ММИ хисабына криоконсервацияләнгән эмбрионнарны куллану белән программа уздырганда 2 страза катырыла.

15. Яхшы сыйфатлы эмбрионнарны криоконсервацияләү өчен стразалар саны 2 (ике) артса, калган эмбрионнар мәгълүматлаштырылган ризалык буенча клиниканың түләүле хезмәтләре кысаларында пациентканың шәхси акчалары хисабына криоконсервацияләнергә мөмкин.

16. Пациентка теләге буенча ММИ программасы акчалары хисабына алынган ооцитларның бер өлеше пациентканың шәхси акчалары һәм Россия Федерациясе законнарында каралган башка акчалар хисабына криоконсервацияләнергә мөмкин.

17. Эмбрионнарны криоконсервацияләү ЭКОның 3 этабын үткәргәннән соң («кичектерелгән күчерү») гамәлгә ашырылган очракта, бер криокүчерү 12 ай дәвамында «Көтү битенә» өстәмә куелмыйча үткәрелергә мөмкин.

18. ЭКОның тулы циклын үткәргән очракта («яңа» эмбрионнарны күчерү белән) яки тулы булмаган циклдан соң (криокүчерү) тискәре нәтиҗә булганда һәм криоконсервацияләнгән эмбрионнар булганда, пациентка ЭКО программасын үткәргән клиникада «Криокүчерү буенча көтү битенә» кабат басарга мөмкин.

19. Уздырылган «яңа» эмбрионнарны күчерү яки криокүчерү программасыннан соң йөклелек барлыккка килү очрагында, криоконсервацияләнгән калган эмбрионнар булганда пациентка ЭКО программасын үткәргән клиникада «Криокүчерү буенча көтү битенә» кабат басарга мөмкин.

20. Теләсә кайсы вакытта йөклелек өзелгән очракта, криоконсервацияләнгән эмбрионнар булганда пациентка ЭКО программасын үткәргән клиникада «Криокүчерү буенча көтү битенә» кабат басарга мөмкин.

21. Эмбрионнарны криоконсервацияләү планлаштырылган пациентлар клиниканың прайсына туры китереп эмбрионнарны саклауны түлиләр.

22. Әгәр эмбрионнар гаризада күрсәтелгән саклау срогы дәвамында кулланылмаса, пациентлар саклау вакытын озайту турында карар кабул итәләр, гаризаны язалар һәм алга таба саклау өчен 100% күләмендә түлиләр.

23. Программаның 2 этабын үткәргәннән соң (овуляцияне стимуллаштыру һәм фолликуллар пункцясе) пациентканың ооцитлары алынмаган очракта, витрификацияләнгәннәрне (туңдырылган донор ооцитларын) куллану мөмкин һәм дәвалауны ММИ акчалары хисабына тәмамлау (3 этап – ооцитларны аталандыру, 4 этап – эмбрионнарны күчерү) мөмкин (тариф 1,0). Бу вакытта витрификацияләнгән ооцитлардан файдалану пациентканың шәхси акчалары яисә Россия Федерациясе законнарында каралган башка акчалар хисабына гамәлгә ашырыла.

24. Пациентканың эмбрионга плантация алдыннан генетик тест үткәрү өчен медицина күрсәтмәләре булган очракта, ЭКО программасын 1, 2 һәм 3 этап (овуляцияне стимуллаштыру, ооцитлар пунциясе һәм аталандыру) һәм барлык эмбрионнарны криоконсервацияләү белән төгәлләргә мөмкин (тариф 1,0).

25. Бу очракта плантация алыннан генетик тест пациентканың шәхси акчалары яисә Россия Федерациясе законнарында каралган башка акчалар хисабына үткәрелә.

26. Ир-ат балага уза алмавының авыр формасы булган очрагында ЭКО программасында донор спермасын куллану мөмкин, ул пациентның шәхси акчалары яисә Россия Федерациясе законнарында каралган башка акчалар хисабына түләнә.

27. ЭКО процедурасын үткәргән медицина оешмасының учет документлары булып «ЯРТ алымнарын кулланганда амбулатор авыруның медицина картасына күрсәтмә бит» (2012 елның 30 октябреннән № 107н РФ ССМ боерыгы) тора.

28. ММИ программасы акчалары хисабына ЭКО процедурасы тәмамланганнан соң пациентка ЭКО процедурасын уздырган медицина оешмасында 21 көнгә кадәр эмбрионны күчергәннән соң аналык куышлыгында аталанган күкәйне визуализацияләү белән кече оча органнарының контроль ультратавыш тикшерүенә кадәр күзәтелә.

29. Медицина оешмасының җаваплы заты ай саен отчет аеннан соң килә торган айның 27нче числосына кадәр Республика комиссиясенә әлеге боерыкка кушымта № 11, 15, 16, 20 туры китереп ЭКО алымы белән дәваланган пациентларның саны һәм үткәрелгән дәвалау нәтиҗәләре турында белешмәләр тапшыра.

30. ЭКО ярдәмендә балага уза алмауны дәвалау нәтиҗәлелеге критерийлары булып тора:

- башланган цикллар санына клиник йөклелекләр саны;
- булып чыккан күчерүләр санына клиник йөклелекләр саны.

31. Әлеге кушымтаның 7 пунктында күрсәтелгән пациент документлары исемлеге 5 ел эчендә ЭКО процедурасын үткәргән медицина оешмасында саклана.

2019 елның 12 декабреннән
№ 2464 ТР Сәламәтлек саклау
министрлыгы боерыгына
Кушымта № 4

Балага уза алмауны дәвалаганда ярдәмче репродуктив технологияләр кулланy белән медицина ярдәмен күрсәтү буенча Республика Комиссиясе турында нигезләмә

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Республика Комиссиясе ММИ программасы кысаларында медицина оешмаларында ЭКО процедурасын түләүсез уздыру хокукына ия булган пациентларны – Татарстан Республикасы яшәүчеләрен сайлап алу максаты белән оештырылган коллегиаль орган булып тора.

1.2. Республика Комиссиясе составы Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы боерыгы белән раслана. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы Комиссиясе рәисе итеп Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының репродуктив сәламәтлек буенча баш штаттан тыш белгече билгеләнә.

2. Республика Комиссиясе вәкаләтләре

2.1. ММИ программасында катнашучы медицина оешмаларына ЭКО процедурасын үткәрүгә мохтаҗ пациентларны сайлап алу һәм җибәрү.

2.2. Мәҗбүри медицина иминияте акчалары хисабына ЭКО процедурасын уздыру өчен пациентларны сайлап алуны һәм җибәрүне оештыру мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы медицина оешмалары җитәкчеләренең, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының баш штаттан тыш белгечләренең эшчәнлеген координацияләү.

2.3. Мәҗбүри медицина иминияте акчалары хисабына ЭКО процедурасын үткәрүгә мохтаҗ пациентларны җибәрү мәсьәләләре буенча медицина оешмалары белән үзара хезмәттәшлек итү.

2.4. Медицина оешмаларында ММИ программасы акчалары хисабына ЭКО процедурасын уздыру һәм ЭКО процедурасын уздырганнан соң пациентларга медицина ярдәме күрсәтү мониторингын алып бару.

2.5. Татарстан Республикасы медицина оешмаларында ЭКО процедурасын уздырганда медицина ярдәмен күрсәтүне оештыру һәм сыйфатын яхшырту мәсьәләләре буенча тәкъдимнәр әзерләү.

3. Республика Комиссиясе хокуклары

Республика Комиссиясе:

3.1. Комиссия утырышларында мәҗбүри медицина иминияте акчалары хисабына ЭКО процедурасын уздыру өчен медицина оешмаларына җибәрү мәсьәләсе буенча мөрәҗәгать иткән пациентларның документларын карап тикшерә.

3.2. ММИ программасы акчалары хисабына ЭКО процедурасын уздыру өчен пациентны медицина оешмасына җибәрү өчен күрсәтмәләрнең булуы (булмавы) турында карар кабул итә.

3.3. Пациентны «Көтү битенә» кую турында карар кабул итә.

3.4. Пациентны «Көтү битенә» куюдан баш тарту турында карар кабул итә.

3.5. ММИ программасы акчалары хисабына ЭКО процедурасын уздыру буенча эшне оештырганда Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының баш штаттан тыш белгечләрен, шулай ук пациентлар теләге буенча ЭКО процедурасын уздыру планлаштырыла торган медицина оешмалары белгечләрен эшкә җәлеп итә.

3.6. Пациентларны ММИ программасы акчалары хисабына ЭКО процедурасын уздыру өчен күрсәтмәләр булу турындагы мәсьәләне хәл итү максаты белән өстәмә тикшерү уздыру өчен Татарстан Республикасы медицина оешмаларына җибәрә.

3.7. ММИ программасы акчалары хисабына ЭКО процедурасын уздыру өчен пациентны медицина оешмасына җибәрү өчен күрсәтмәләр булмаган очракта, пациентны алга таба күзәтү һәм (яки) дәвалау буенча рекомендацияләр бирә.

3.8. Мәҗбүри медицина иминияте акчалары хисабына ЭКО процедурасын сайлап алуны һәм үткәрүне оештыру буенча бәхәсле мәсьәләләрне карап тикшерә, кирәк булган очракта, консилиумнар оештыра.

## 4. Республика Комиссиясе эшен оештыру

4.1. Республика комиссиясе утырышы кирәк булган саен, кимендә кварталга бер тапкыр, үткәрелә.

4.2. Комиссия утырышында Республика Комиссиясе составының кимендә 2/3 өлеше катнаша.

4.3. Мәҗбүри медицина иминияте акчалары хисабына ЭКО процедурасын уздыру өчен пациентны җибәрү турындагы мәсьәләне Республика Комиссиясендә карап тикшерү өчен нигез булып түбәндәге документлар тора:

1) табиблар комиссиясе карары беркетмәсе;

2) пациент документлары күчермәләре:

- паспорт;
- пациентның мәҗбүри медицина иминияте полисы;
- пациентның мәҗбүри пенсия иминияте таныклыгы;

3) пациентның медицина документларыннан, диагнозны раслый торган лаборатор, инструменталь һәм башка төр тикшеренүләрнең нәтиҗәләре белән, сәламәтлек саклау оешмасы җитәкчесенең имзасы белән оешманың мөһере белән расланган өземтә;

4) мәҗбүри медицина иминияте акчалары хисабына ЭКО процедурасын уздыру өчен пациент гаризасы;

5) шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык.

4.4. Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) «Көтү битенә» куярга;

2) пациентны мәҗбүри медицина иминияте акчалары хисабына ЭКО процедурасын уздыру өчен медицина оешмасына җибәрергә;

3) ЭКО процедурасына җибәрүдән баш тарту, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп:

- күрсәтмәләр булмау;
